СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2023 Баулы шәһәре № 224

Баулы муниципаль районы Советының “Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында” 2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Баулы муниципаль районы Советының “Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында” 2021 елның 14 декаберндәге 93 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәдә:

5.4. һәм 5.5. пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары) тарафыннан карала.

5.5. Башкарма комитет, Башкарма комитет җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Баулы муниципаль районы Башлыгы тарафыннан карала.»;

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү;

2) алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда һәм (яки) аннан алда килгән шул ук чор белән чагыштырганда, вакыт берәмлегенә (ай, квартал) мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы, муниципаль торак контроле органына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки бина хуҗалары булган оешмалардан, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучы гражданнар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат;

3) Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

4) Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча, контрольдә тоту затының идарәсендә торган, күпфатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасын чакыру очрагы теркәлгән;

5) торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында, күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен, алдагы, шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда, 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров